КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 22 февраль г.Казань № 90

Казан шәһәре, Маршал Чуйков урамы, 54 нче йорт адресы буенча урнашкан бина фасадына мемориаль такта кую турында

Татарстан Республикасының атказанган табибы, Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау министры (2018 - 2023 еллар) Садыйков Марат Наил улы истәлеген мәңгеләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Казан шәһәренең «М.Н.Садыйков исемендәге 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Казан шәһәре, Маршал Чуйков урамы, 54 нче йорт адресы буенча бина фасадына рус һәм татар телләрендә түбәндәге текст белән мемориаль такта кую турында тәкъдимен кабул итәргә:

«В 2008 – 2018 гг.
главным врачом городской
клинической больницы № 7
г.Казани работал
заслуженный врач РТ,
кандидат медицинских наук,
министр здравоохранения РТ
в 2018 – 2023 гг.
Марат Наилевич Садыков

___________

2008 – 2018 елларда
Казан шәһәренең
№ 7 шәһәр клиник хастаханәсенең
баш табибы булып
ТРның атказанган табибы,
медицина фәннәре кандидаты,
2018 - 2023 елларда
ТРның сәламәтлек саклау
министры Марат Наил улы
Садыйков эшләде».

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгын мемориаль тактаны балансnúmта тотучы итеп билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин